# Дәджәл Фетнәсе

## المسيح الدجال

### اللغة التترية

ALSARHAAN.COM

شرٌّ غائبٍ منتظر
وأعظم فتنةٍ على وجه الأرض منذ خُلِقَ آدم إلى قيام الساعة

Адəм галяйхиСсəлам барлыкка китерелгəннəн бирле Кыямəт көненə хəтле җирдə буласы иң бөек, иң явыз фетнə.

وما من نبي بُعِثَ إلا أنذر قومه به وحذرهم منه. إنه الأعور الدّجال مدعي الألوهية كذبا واضلالا.

Һəм нинди генə пəйгамбəр килмəсен, ул үз халкын шушы килəсе зур фетнə хакында, ягъни үзен Аллаһ дип əйтүче, сыңар күзле, ялганчы дəджəлнең чыгуы турында кисəтте.

قال النبي صلى الله عليه وسلم:
إنْ يَخْرُجْ وَأَنَا فِيكُمْ، فأنَا حَجِيجُهُ دُونَكُمْ، (اياكفيكم اياه)؛ وإنْ يَخْرُجْ وَلَسْتُ فِيكُمْ، فَامْرُؤٌ حَجِيجُ نَفْسِهِ، وَاللَّهُ خَلِيفَتي علَى كُلِّ مُسْلِمٍ

Пəйгамбəребез ﷺ əйтте: "Əгəр, мин сезнең белəн булганда, Дəджəл килеп чыкса, мин сезсез аның белəн көрəшермен, ягъни аңа каршы сезнең өчен мин җитəмен. Əгəр ул мин булмаганда чыкса, һəрбер кешегə үз җаны белəн көрəшергə туры килер, һəм Аллаһ – һəрбер мөселманны саклауда минем ярдəмчем.

ومن صفاته أنه رجل أحمر قصير عريض قد انحسر شعره عن جبهته وكُتِبَ بين عينيه كافر.

һәм Дәджәлнең сыйфатларыннан – ул кызыл төсле, кечкенә буйлы, таза ир-ат, чәчләре маңгаеннан төшеп торыр, һәм ике күзе арасында "кәфер" дип язылган булыр.

يقرأها كل مسلم كاتب وغير كاتب.

Аны һәрбер мөселман укый алыр: яза алганы да, яза алмаганы да.

ومن صفاته كذلك أنه ممسوح العين اليمنى. كأن عينَه عنبةً طافئة.

һәм шулай ук аның сыйфатларыннан – уң күзенең булмавы, әйтерсең лә аның күзе акай йөзем шикелле.

وهو عقيم لا يولد له

һәм ул нәселсез, ягъни баласыз булыр.

وخروج دجال من أشراط الساعة الكبرى.

һәм Дәджәлнең чыгуы Кыямәт көненең зур галәмәтләреннән булып тора.

ويكون خروجه من جهة المشرق من خراسان فيتبعه سبعون الفا من يهوديّ اصبهان.

Ул көнчыгыштан, Хорасан исемле җирлектән килеп чыгып аның артыннан җитмеш мең Исбахан яһүдиләре иярер.

ثم ينطلق داخلا الجزيرة مما بين الشام والعراق قاصدا مكة والمدينة بسوء.

Шуннан соң ул Шәм һәм Ирак арасында булган җирлек аша, золымлык кылу нияте белән Мәккәгә һәм Мәдинәгә таба юл тотар.

فتصده الملائكة بسيوفها

Ләкин, фәрештәләр кылычлар белән аңа каршы чыгып бу ике шәһәргә керергә рөхсәт итмәсләр.

وإنّ من فتنته أن يمر بالحي فيصدقونه فيأمرَ السماء فتمطر والأرض فتنبت ، فتمتلئ ماشيتهم من الشباع ، ثم يمرَ بالحي فيكذبونه فينصرف عنهم فيصبحوا مُمْحِلِين ليس بأيديهم شيء من أموالهم

Шулай ук аның фетнәсеннән булып тора: ул берәр җирлек аша үткәндә, анда яшәүчеләр аңа иман китерсәләр, ул шунда ук аларга күктән янгырлар яудырып, җирдән үсемлекләр үстерер, һәм терлек-туарлары көтүлектән тазарып кайтыр. Һәм шулай ук башка җирлетән үткәндә, анда яшәүчелар аңарга иман китермәсәләр, ул аннан китеп барыр, шушы җирлеккә корылык килеп, аларның мал-мөлкәтләреннән бернәрсә дә калмас.

ومن عظيم فتنته أن يخرج إليه شاب من المؤمنين قد عرفه بعلامته وصفته فيقول: أشهد أنك الدّجال الذي حدثنا رسول الله صلى الله عليه وسلم حديثه.

Һәм иң бөек фетнәдән — мөселманнардан булган бер яшь егет Дәдҗәлне кыяфәтеннән һәм билгеләреннән танып: "Син, безгә Пәйгамбәребез ﷺ хәбәр иткән, Дәдҗәл икәненә шаһәдәт китерәм" - дип әйтер.

فيقول الدجال :ارأيتم إن قتلتُ هذا ثم أحييته أتشكون في الأمر؟

Һәм шуннан соң Дәджәл үзенә ияргән кешеләргә: "Әгәр мин бу егетне үтереп, соңыннан терелтсәм, сездә шик калыр микән?" - дип әйтер.

فيقولون: لا.

Алар: - "Юк!",- дип әйтерләр.

قال : فيقتله ثم يحييه.

Һәм ул аны үтерер, һәм шунда ук терелтер.

فيقول الشاب المؤمن حين يحييه :
والله ما كنت فيك قط أشد بصيرة مني الآن.

Һәм бу мөэмин егет терелгәч әйтер: " Аллаһ белән ант итәм, беркайчан да әле хәзерге кебек синең шушы Дәджәл икәнеңә ныклы инану юк иде".

قال: فيُريد الدّجال أن يقتله ؛ فلا يُسلط عليه.

Һәм шуннан соң Дәджәл аны яңадан үтерергә теләр, ләкин моны булдыра алмас .

وبينما الدّجال يَعيثُ يمينا وشمالا
إذ يَنزل عيسى ابن مريم عليه السلام فيدركه ، فإذا رآه عدوُّ الله ذاب كما يذوب الملح في الماء ؛

Шулчак Дәджәл уңга да, сулга да явызлыгын күрсәтеп юлын дәвам итәр. Һәм шуннан соң, Аллаһның пәйгамбәре
Мәрьям улы Гайсә җиргә төшеп, Дәджәлне үтерер. Аллаһның дошманы Гайсәне күрү белән, суда тоз эрегән шикелле юкка чыгар.

فلو تركه لنذابَ حتى يهلك، ولكن يقتله الله بيده فيريهم دمه في حربته.

Әгәр Гайсә, гәләйһиссәләм аны калдырган булса да, Аллаһ Дәджәлне юкка чагарыр иде, әмма дә ләкин Аллаһ Дәджәлне пәйгамбәре кулы белән үтерергә теләде.х

إنّ العِصمةَ من الدّجال وفتنته بأمور منها: -

Дәджәлдән һәм аның фетнәсеннән саклану чаралары бар.

التمسك بالإسلام والتسلح بالإيمان.

معرفة الله تعالى بأسمائه وأوصافه.

وأنه تعالى منزه عن كل عيب ونقص.

һәм шушы чаралардан:

— Дингә ныклап ябышып иман белән кораллану.

— Аллаһ турында, Аның исемнәрен һәм сыйфатларын өйрәнеп гыйлемеңне арттыру.

— Аллаһның барлык кимчелек-җитешсезлекләрдән пакь булуына ныклап ышану.

- حفظ عشر آيات من أول سورة الكهف او اخرها ، فمن حفظ عشر ايات اول سورة الكهف. وفي رواية من آخرها عصم من الدجال.

— Кәһф сүрәсенең беренче ун аятен яки ахыргы ун аятен ятлау. һәм кем дә кем Кәһф сүрәсенең беренче ун аятен, икенче риваяттә хәбәр ителгән шикелле ахыргы ун аятен ятласа - Дәҗҗәл фетнәсеннән сакланыр.

التعوذ بالله من فتنة الدجال. خاصة بعد الفراغ من تشهد الصلاة الاخير.

— Дәдҗәл фетнәсеннән Аллаһка сыену, бигрәк тә намаз ахырында.

قال النبي صلى الله عليه وسلم إذا تشهد أحدكم فليستعذ بالله من أربع. يقول : اللهم إني أعوذ بك من عذاب جهنم ومن عذاب القبر ومن فتنة المحيا والممات ومن شر فتنة المسيح

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Әгәр берәрегез тәшәһүттә утырса, дүрт нәрсәдән Аллаһка сыенып, шушы сүзләрне әйтсен: "Йә Аллаһ, хакыйкатьтә мин Сиңа җәһәннәм газабыннан, кабер газабыннан, дөнья һәм үлем фетнәсеннән һәм Дәдҗәл фетнәсеннән сыенамын"